ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.18а, д.Малые Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 18а йорт, Кече Урыссу авылы.,
423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**

**№ 55** **7 ноябрь 2019 ел**

«Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссуы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча халык җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябреннән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Уставының 14 статьясына ярашлы, Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2019 елның 22 ноябренә 18.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссуы торак пунктында Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Кече Урыссуы авылы, Совет урамы, 21А адресы буенча урнашкан МФЦ бинасында үзара салым кертү соравы буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Ютазы муниципаль районының Кече Урыссуы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешенең 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия сорауны хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

-Кече Урыссуы торак пунктының Тукай урамы буенча вак таш җәелгән юлны асфальтлауга.

« ӘЙЕ» “ЮК".

2. Ташкичү авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, һәм карар рәсми кабул ителгән көннән соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, 5 көн эчендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

"Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль

берәмлеге Башлыгы Р.К. Валеев.